■ Илхам

# САБЫРЛЫК - САРЫ АЛТЫН...

Дилә БУЛГАКОВА,
шагыйрә

Көтеп алган изге Рамазан айыбыз да хушлашты. Бу юлы һәр бер ураза тоткан көнебез олы бәйрәм булды. Әлхәмдүлиллаһ, сабыр, матур итеп, ифтарлар үткәрдек. Һәр бер ураза тоткан көндәребезне укыган намаз, догаларыбызны, тәрәвих намазларыбызны кабул гына итсен Аллаһы Тәгалә. Мәчетләребездә гаит бәйрәмнәребез мөселманнар өчен олуг зур бәйрәм булды. Ул көнгә яңы киемнәр тектереп киенәбез, ясанабыз, башыбызга яңа яулыклар бәйлибез. Бер-беребезгә бүләкләр бирештек, гает чәйләренә йөрештек. Шулай ук бу айда ятимнәрне, зәгыйфләрне, мохтажларны шатландырдык: табыннар корып, садәкәләр өләштек.

Мин дә Рамазан аенда тәвәкәлләп Янавылда яшәп иҗат иткән якын дусларым - каламдәшләрем талантлы шагыйрә Кәүсәриә Шәфикова һәм шагыйрь Рәфис Мөхәмәтдинов янына барып, күрешеп, серләшеп язган иҗат җимешләребез белән бүлешеп кичләребезне үткәрдек, бер-беребезне изге мөбарәк аебыз белән тәбрикләштек.

Минем газиз дусларымның сабырлыгына сокланып туялмыйм. Аллаһы Тагаля аларны сабырлыклардан гына яралткандыр, аера гына күрмәсен.

Кәүсәриә Янаул районының Исәнбай ауылында 1948 йылда доньяга килә. Әнкәсе Тәскирә апа - җигәрле, акыллы, тыйнак, түземле апа - кызчыгы теле ачылу белән, хәрефләр өйрәтә. Ә әтисе Фидан абый - тәҗрибәле экономист, алтын куллы кеше була. Ләкин, кызганычка каршы, аларның фәрештәле җылы өйләренә кот очкыч чир кереп бишектәге сабыйга сарыла. Өйнең ямен, ашның тәмен югалткан Тәскирә апа белән Фидан абый югалып калалар - кызларның бишегенә кунаклаган аяусыз тәкъдир-күлмәген киеп, шакшы куллары белән бишектәге әле ике яше дә тулмаган Кәүсәриягә кагылып гариплә тә һәм гомерлеккә бишек коляскада яшәргә мәҗбүр итә.

Аллаһы Тәгалә аңа яшли язу сәләте бирә: яза белү белән шигерләр иҗат итә, пумала алып рәсемнәр ясый, канатлана - яшәү өчен көрәшә. 60 йылдан ашыу бишек колясксендә иҗат итә... Кеше ярдәменә мохтаҗ шагыйрәбез, уннан ашыу китап авторы. Әнкәйе әхирәт йортына күчкәннән соң, Кәүсәрияне Зиния апасы 13 ел буйы тәрбияләй, кызганычка каршы ул да вафат булып кала.

Кәүсәрия әтисе белән Исәнбай авылыннан Янаулга күчәләр. Куанып кына яшәп ятканда 80 яшендә Фидан абый да донъя куя. Хәзерге көндә якташы Фатыма ханым карый, тәрбиәли.

"Аяксыз, кулсыз яшәүгә караганда, чит кешеләрдән тилмереп ярдәм көтүдән дә авыр нәрсә юк", - ди Кәүсәриә. Каләмдәшемнең бер кайчан да яшен күргәнем юк. Кәүсәриә Шәфикова Янавыл шәһәренең социаль хезмәткәрләренә зур рәхмәтен белдерә.

Кәүсәриәнең күршесендә шагыйрь Рәфис Мөхәмәтдинов яши, ул да кеше ярдәменә мохтаж. Никахлы шагыйрь елмаеп безгә: "Сансыз йыллар үтте инде. Шәмсүл Шәрифуллин безнең никахыбыззы укыган иде. Без бергә иҗат итәбез, ишегебез дә ябылганы юк, бер-беребезгә кунакка йөрешәбез", - тип сөйләде.

"Без теш кысып булса да түзәбез, якты донъяла йәшәгәнебез өчен Аллаһы Тәгаләбезгә рәхмәтлебез. Аллаһы Тәгалә безгә язу, рәсем төшерү сәләте бирде. Без бик бәхетлебез. Раббыбыз безне бар нәрсәдән дә мәһрүм итсә дә, сөйләшәбез, Нәсер, шигырлар иҗат итеп куанабыз. Җырларыбызны җырлыйлар, мәктәпләрдә очырашуларга чакыралар, туйларда фатыхаларыбызны алалар, төрлө шәһәр-ләрдән килгән концертларга чакыралар - шул үзе куаныч түгелме ни, - дип куана минем каләмдәшләрем.

Ана шундый талантлы, көчле рухлы, язмышларына зарланмай, һәр яңа таңга куанып, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен әйтеп, биргән ризыкка, һәр чак ярдәм итеп торган караучыларына рәхмәтләрен әйтеп яшәүсе соклангыч дусларым - каләм-дәшләрем бар!

Дусларыма сабырлык, иҗади уңышлар, бәхет телим. Теләгән теләкләре, күз карашлары белән тарткан тәсбихләре, көч-кеүәт биреп, нурын чәчеп торсын. Амин!

■ Ҡорбан ғәйете мөбәрәк булһын!



# Ҡорбан салайыҡ, сауаптарын алайыҡ!

Ҡорбан һүҙе "яҡынайыу", "яҡыныраҡ булыу" тигәнде аңлата. Дини термин булараҡ, был йөрәк менән Бөйөк Аллаһы Тәғәләгә яҡынайыу өсөн ғибәҙәт ҡылыу ниәтендә тәғәйен бер ваҡытта ҡорбан салыу. Ҡорбан Исламда мөлкәт менән ҡылынған ғибәҙәттәрҙең береһе. Был Аллаһы Тәғәләгә биргән ниғмәттәре өсөн рәхмәт белдереү. Ҡорбан шулай уҡ Алланың берҙән-бер булыуын тәүгеләрҙән аңлатыусы, Раббыбыҙҙың яҡын ҡоло Ибраһим ғәләйһисәләмдең иҫтәлегенә лә арнала. Бәйғәмбәребеҙ (салаллаһу ғәләйһи вә сәлләм) әйткән: "Ҡорбан - ул атабыҙ Ибраһимдың (ғәләйһисәләм) сөннәте". Был турала Ҡөрьәндә лә әйтелә: "Һәм ул (Ибраһим) улын йөҙ түбән яткырҙы. Беҙ әйттек: "Эй, Ибраһим! Һин төшөңә тоғро ҡалдың. Шөбһәһеҙ, Беҙ изгелекле ғәмәлдә булғандарҙы бүләкләйбеҙ", - тинек. Хаҡтыр, был ҡәтғи бер һынау ине. Беҙ уға оло бер ҡорбанлыҡ (тәкә) ебәрҙек. Унан һуң килгәндәргә Беҙ уның тураһында яҡшы иҫтәлектәр ҡалдырҙыҡ. (Беҙҙән) Ибраһимға сәләм. Беҙ изгелек ҡылғандарҙы ана шулай бүләкләйбеҙ ("Әс-Саффат", 99-110).

Шуның өсөн Мәккә янындағы Минә үҙәнендә Ҡорбан тантаналарынан һуң хаж ҡылыусылар Ҡәғбәтулла алдындағы "Ибраһим урыны"на килә һәм Мәҙинәләге Мөхәммәт бәйғәмбәр ҡәберенә йүнәлә. Хажға бармаған мосолмандар иһә туған-тыумасаларының һәм яҡындарының ҡәберен зыярат ҡыла, күстәнәстәр һәм бүләктәр алып, туғандарының һәм дуҫтарының хәлен белешеп сыға.

Беҙ Аллаһтың малдың итенә лә, ҡанына ла мохтажлығы юҡ икәнде онотор ға тейеш түгелбеҙ. Уға тик ҡолоноң ниәте, ихласлығы һәм тәҡүәлеге генә барып етер. Ҡөрьәндә ғәмәлдең нигеҙен тәшкил иткән был ниәт һәм тәҡүәлек шулай билдәләнә: "Уларҙың ни ите, ни ҡаны Аллаһҡа түгел, Уға фәкәт һеҙҙең тәҡүәлелегеҙ генә барып ирешә..." ("Хаж", 37).

Бәйғәмбәребеҙ (салаллаһу ғәләйһим вә сәлләм) ҡорбан салыуҙың мотлаҡ икәнлеген билдәләп үтә: "Кем мөмкинлеге булып та ҡорбан килтермәй, шул беҙҙең мәсеткә яҡынаймаһың", - тигән ул.

Шуға күрә, һәр мосолман Ҡорбанға етди ҡарарға тейеш. Тик ихлас инаныусылар ғына, Аллаһы Тәғәләгә яҡынайыу маҡсаты менән Ҡорбан сала. Хәҙистәрҙә: "Ҡорбанға эре малдарҙы һуйығыҙ, сөнки улар Сират күпере аша үткән саҡта һеҙҙе алып сығасаҡ", "Ҡорбандың һәр йөнөнә тиклем бүләкләү бар", - тип әйтелә.

## Байрам көндәрендә эшләргә кәрәк булған ғәмәлдәр:

- Байрам төндәрен доғала һәм ғибәҙәттә үткәрергә, ҡаза намаҙҙарын ҡылырға, Ҡөрьән уҡырға һәм тәүбә итергә кәрәк, сөнки байрам төнөндә ҡылған доғалар ҡабул була.
- Байрам иртәһендә иртәрәк торорға, тәһәрәт алырға.
- Таҙа һәм яңы кейемдәр кейергә.
- Йылмайырға һәм шат йөҙлө булырға.
- Ярлыларға күберәк саҙаҡа таратырға.
- Байрам намаҙына барған ваҡытта юлда тәкбирҙәр әйтергә.
- Әгәр ҙә кеше Ҡорбан салдырырға уйлай икән, үҙенең Ҡорбан итен тәмләп ҡарамайынса, ризыҡтан баш тартып тороу яҡшыраҡ.
- Ҡорбан итен ашарға, сөнки Бәйғәмбәребеҙ (салаллаһу ғәләйһи вә сәлләм) шулай эшләгән.
- Кешеләргә ҡарата йомарт булырға.

■ Гыйбадәт

# Намаз - Раббыңның чакыруына юнәлү

Намаз гыйбәдәте бертөрле күңел ачылуы һәм тынычлануга вәсилә булган кадәр Раббының чакуруына юнәл дигән мәгънәгә дә килә. Җир йөзендә көнөнә биш мәртәбә манаралардан "Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр" дип, азан мөхәммәди укыла, һәм бөтен мөселманнар намазга чакырыла.

Аллаһу Тәгалә намаз гыйбәдәте аркылы безне үзенең рәхмәтенә чакыра. Төп дәгъвәт итүчеләрнең килгән кунакларны ишек төбендә каршы алганнарны, һәм матур сүзләр әйтеп, төрле икрамнар белән аларны зурлаганнары, һәм килгән кешеләр арасында да берсен берсеннән аермыйча бөтенесен бер тигез итеп караганнары кебек, көненә биш мәртәбә манаралардан күкләргә менә торган азан тавышлары без мөэ-миннәрне Аллаһы Тәгәләнең хозурына мәгънәви икрамнарына, рәхмәтенә чакыра. Коръән Кәрим азан мөхәммәдинең дәрәҗәсен аңлаткан вакытта: "Аллаһка чакыра торган сүзләрдән яхшырак сүзнең булуы мөмкинме?" - дип әйтә ("Фуссиләт", 33).

Мәчетләргә дәгүвәт кылучы Аллаһ (ж.ж.) анда баручыларның кулларын буш кайтармаячак, мәңге игелек, киң күңеллелеге һәм рәхмәте белән колларының рух һәм күңел дөньяларына кирәк булган мәгънәви нурларны тутырачак. Аларның күзләреннән пәрдәне ачып, мәңге галәмне карауларын мөмкин кылачак. Алар белсеннәр яки белмәсеннәр, бер мигъраж кылу киң күңеллеклек белән аларны шәрәфләндерәчәк.

Кол Аллаһның бу дәгъвәтен кабул итеп, аңа юнәлгән вакытта, әгәр дөрес итеп укыган булса, намазның бертөрле баскычка әйләнгәнен һәм аны Аллаһка таба күтәргәненә шаһит булачак. Хәтта шундый күтәреләчәк ки, Раббысынын аңа бик якын икәнен бөтен тәне белән хис итәчәк.

### Намаз кешене тынычлыкка чакыра

Намаз кешене күренә торган пычраклардан коткарганнан соң, рух һәм йөрәкне юып, Хозуры Кибриягә (Аллаһның хозурына) кабул ителүгә лаек хәлгә әзерләр. Бу яклап ул кешенең мәгънәви тынычлыкка ирешеүен тәэмин итә торган аерым бер гыйбадәт. Кеше намаз аркылы һәм күңел ягыннан тыныч булыр, һәм Раббысының ризалыгына ирешер.

Көнөнә биш вакыт укылган намаз мәгънәви яктан күтәрелүне күңелдән теләүчеләр өчен һәр көнне мигъраҗ булып, алар өчен һәр көнне баскыч вазифасын алып барыр. Шуның өчен Әфәндебез (с.г.в.) намаз гыйбадәте өчен "Күземнең нуры", дип әйткән. Каинәтнең Әфәндесе (с.г.в.) Мигъраҗ вакыйгасында Җәбрәил (г.с.)не дә артта калдырып, аннан да биегрәк урыннарга менгән Аллаһу Тәгалә тарафыннан үзенә әйтеләчәк хәбәрне бик нык көтеп алган вакытта, намаз бүләк буларак бирелеп, аңа һәм өммәтенә фарыз ителде.

Гүяки Әфәндебез (с.г.в.) бәшәр юлы белән җанлылар арасына кереп, Аллаһка кол булу мәсьәләсендә иң бөек дәрәҗәләргә менгәннән соң, жир йөзендә ничек барырга белә алмаган өммәте өчен котулы вәсиләсен Аллаһу Тәгаләдән сораган. Ул да биш вакыт намазны аңа һәм өммәтенә фарыз итеп, аның бу соравына жавап биргән.